КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 апрель г.Казань № 527

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче; 2020 ел, 24 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 31 май, 422 нче; 2022 ел, 22 февраль, 151 нче; 2022 ел, 9 июль, 660 нчы; 2022 ел, 15 декабрь, 1339 нчы; 2023 ел, 20 март, 298 нче; 2023 ел, 11 июль, 814 нче; 2024 ел, 28 ноябрь, 1073 нче; 2024 ел, 26 декабрь, 1217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган

көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның алтынчы абзацында «10 чара» сүзләрен «җиде чара» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«соңгы өч календарь елда уздырылган чаралар (чараларның исемнәре, урыны, вакыты, шартнамәләр яктылыгында чаралар үткәрү чыгымнары күләме) турында белешмә кәгазьләре;»;

48 пунктта «исәп-хисап» сүзләрен төшереп калдырырга;

53 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«53. Субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән өчен түбәндәге җаваплылык чаралары карала:

субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтару – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта;

субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү нәтиҗәләренең ирешелмәгән күрсәткеченә пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә кире кайтару – субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта;

субсидия алучы, әгәр килешүдә билгеләнгән срокларда субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәгән очракта, кичектерелгән һәр көн өчен кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының пеня исәпләнә башлау датасына гамәлдә булган төп ставкасыннан бер бөтен меңнән өч йөз алтмыш күләмендә пеня (субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүнең план буенча датасыннан соң килә торган беренче көннән алып субсидияне (субсидиянең бер өлешен) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару көненә кадәр) түли.

Министерлык әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган вакыйгалар ачыкланган көннән алып 30 календарь көннән артмаган срок эчендә субсидия алучыга әлеге таләп алынган көннән алып 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.»;

54 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин